МИНИСТЕРСТВО ЗЕМЕЛЬНЫХ И ИМУЩЕСТВЕННЫХ ОТНОШЕНИЙ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ҖИР ҺӘМ МӨЛКӘТ МӨНӘСӘБӘТЛӘРЕ МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

от 13.12.2018 № 610-пр

Казан ш.

«Татарстан Республикасы милкендә булган мөлкәтне арендага бирүне килештерү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының 2018 елның 17 маендагы № 1315-р карары белән расланган Татарстан Республикасы милкендә булган мөлкәтне арендага бирүне килештерү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү турында

Законнарга үзгәрешләр кертелү белән бәйле рәвештә б о е р а м:

«Татарстан Республикасы милкендә булган мөлкәтне арендага бирүне килештерү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының 2018 елның 17 маендагы № 1315-р карары белән расланган Татарстан Республикасы милкендә булган мөлкәтне арендага бирүне килештерү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына кертелә торган тәкъдим ителгән үзгәрешләрне расларга.

**Министр** **А.К.Хамаев**

Татарстан Республикасы
Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре
министрлыгының
13.12.2018 № 610-пр
карары белән расланды

«Татарстан Республикасы милкендә булган мөлкәтне арендага бирүне килештерү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының 2018 елның 17 маендагы № 1315-р карары белән расланган Татарстан Республикасы милкендә булган мөлкәтне арендага бирүне килештерү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына кертелә торган үзгәрешләр

1 бүлектә:

1.3.4 пунктта:

беренче абзацны «Дәүләт хезмәте турында» дигән сүзләрдән соң «, шулай ук, Министрлыкның урнашкан урыны һәм эш графигы турында» дигән сүзләр белән тулыландырырга;

тугызынчы абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Мәгълүмати стендларга Татарстан Республикасының дәүләт телләрендә урнаштырылган мәгълүмат әлеге Регламентның 1.3.1, 2.1, 2.3, 2.4, 2.5, 2.8, 2.10, 2.11, 5.1 пунктлардагы дәүләт хезмәте турындагы белешмәне үз эченә ала.»;

1.4 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.4. Дәүләт хезмәте күрсәтү түбәндәгеләр нигезендә хәл ителә:

Россия Федерациясе Гражданлык кодексы (алга таба – РФ ГК);

«Коммерциячел булмаган оешмалар турында” 12.01.1996, №7-ФЗ Федераль закон (алга таба – №7-ФЗ Федераль закон) (Россия Федерациясе законнары җыелмасы, 1996, № 3, 145 б. кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

«Россия Федерациясендә бала хокукларының төп гарантияләре турында» 24.07.1998, № 124-ФЗ Федераль закон (алга таба – № 124-ФЗ Федераль закон) (Россия Федерациясе законнары җыелмасы, 1998, № 31, 3802 б. кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

«Россия Федерациясендә бәяләү эшчәнлеге турында» 1998 ел, 29 июль, 135-ФЗ Федераль закон (алга таба – № 135-ФЗ Федераль Закон) (Россия Федерациясе законнары җыелмасы, 1998, № 31, 3813 б., кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

«Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектлары (тарихи һәм мәдәни ядкәрләр) турында» 2002 ел, 25 июнь, 73-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба - № 73-ФЗ Федераль закон) (Россия Федерациясе законнары җыелмасы, 2002, № 26, 2519 б., кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

«Дәүләти һәм муниципаль унитар предприятиеләр турында» 14 ноябрь 2002 ел № 161-ФЗ Федераль закон (алга таба - № 161-ФЗ Федераль закон) (Россия Федерациясе законнары җыелмасы, 2002, № 48, 4746 б., кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

«Конкуренцияне саклау турында» 26 июль 2006 ел № 135-ФЗ Федераль закон (алга таба – Конкуренция турында Федераль закон) (Россия Федерациясе законнары җыелмасы, 2006, № 31, 3434, б., кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

«Автоном учреждениеләр турында» 3 ноябрь 2006 ел № 174-ФЗ Федераль закон (алга таба – № 174-ФЗ Федераль закон) (Россия Федерациясе законнары җыелмасы, 2006, № 45, 4626 б. кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәт күрсәтүләрне оештыру турында» 27 июль 2010 ел, № 210-ФЗ Федераль закон (Россия Федерациясе законнары җыелмасы, 2010 ел, № 31, 4179 б. кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

«Россия Федерациясендә мәҗбүри медицина иминиятләштерүе турында» 29.11.2010, № 326-ФЗ Федераль закон (алга таба – № 326-ФЗ Федераль закон) (РФ законнары җыелмасы, 2010, № 49, 6422 б. кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

«Электрон имза турында» 06.04.2011 № 63-ФЗ Федераль закон (алга таба - № 63-ФЗ Федераль закон) (Россия Федерациясе законнары җыелмасы, 2011, № 15, 2036 б. кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

«Күчемсез милекне дәүләт теркәве турында» 13 июль 2015 ел, № 218-ФЗ Федераль закон (Россия Федерациясе законнары җыелмасы, 2015, № 29, 4344 б., кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

«Дәүләт идарәсе системасын камилләштерүнең төп юнәлешләре турында» 07 май 2012, № 601 Россия Федерациясе Президенты Указы (алга таба – РФ Президенты Указы № 601) (Россия Федерациясе законнары җыелмасы, 2012, № 19, ст. 2338);

«Татарстан Республикасы милке белән идарә итү һәм эш итү турында» 2007 елның 26 июлендәге № 35-ЗРТ Татарстан Республикасы Законы (алга таба – ТР Законы № 35-ЗРТ) (Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2007, № 7, 621 б., кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 05.12.2005 № 563 карары белән расланган Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты – Татарстан Республикасы Хөкүмәте Регламенты («Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм боерыклары һәм башкарма хакимиятнең республика

органнары норматив актлары җыентыгы» журналы, 2005, № 47-48, 0985 б., кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы мәсьәләләре» 22.08.2007 ел, № 407 карары белән расланган Татарстан Республикасының Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы турында нигезләмә (алга таба – Нигезләмә) («Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм боерыклары һәм башкарма хакимиятнең республика органнары норматив актлары җыентыгы» журналы, 2007, №37, 1379 б. кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

«Дәүләти (муниципаль) учреждениеләрнең хокукый хәлен камилләштерү белән бәйле рәвештә Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 08.05.2010 № 83-ФЗ Федераль Законны Татарстан Республикасындагы дәүләт учреждениеләрен булдыру, үзгәртеп оештыру, төрен үзгәртү һәм бетерү ягыннан тәртип урнаштыру, шулай ук, Татарстан Республикасындагы дәүләт учреждениеләрен гамәлгә куючының һәм мөлкәт иясенең функцияләрен һәм вәкаләтләрен регламентацияләү ягыннан Татарстан Республикасында гамәлгә ашыру чаралары турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 18.10.2010 № 820 карары (ТР МК карары №820) («Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм боерыклары һәм башкарма хакимиятнең республика органнары норматив актлары җыентыгы” журналы, 2010, № 45, 2039 б., кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

«Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен раслау һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү турында» 02.11.2010 ел, № 880 Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм боерыклары һәм башкарма хакимиятнең республика органнары норматив актлары җыентыгы, 2010, № 46, 2144 б. кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

«Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары дәүләт хезмәте күрсәткәндә ведомоствоара мәгълүмати үзара бәйләнеше тәртибе турында» 07.08.2012, № 674, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары белән расланган Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары дәүләт хезмәте күрсәткәндә ведомоствоара мәгълүмати үзара бәйләнеше тәртибе (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм боерыклары, башкарма хакимиятнең республика органнары норматив актлары җыентыгы, 2012, № 59, 2041 б. кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып).»;

1.6 пунктның икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«күпфункцияле үзәкнең дәүләти һәм муниципаль хезмәт күрсәтүче ераклаштырылган эш урыны – Татарстан Республикасының муниципаль районнардагы (шәһәр округында) шәһәр һәм авыл җирлекләрендә “Дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүче күпфункцияле үзәк эшчәнлеген оештыру тәртипләрен раслау турында» Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2012 елның 22 декабрендәге № 1376 карары белән расланган Дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүче күпфункцияле үзәк эшчәнлеген оештыру тәртипләренең 34 нче пункты нигезендә оештырылган дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүче күпфункцияле үзәкнең территориаль аерымланган структур подразделениесе (офис);»;

2 бүлектә:

2.5 пунктта:

«Стандартка таләпләр эчтәлеге» графасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы милкендә булган мөлкәтне (алга таба – мөлкәт) арендага бирүне килештерү өчен зарури булган документлар:

1. Дәүләт мөлкәтен сатулашу уздыру юлы белән арендага бирүне килештерү турында гариза (1нче кушымта) яки дәүләт мөлкәтен сатулашу уздырмыйча гына арендага бирүне килештерү турында гариза (2нче кушымта).

2. Арендага бирү өчен тәкъдим ителә торган биналарның планнары күчермәләре һәм биналарның юридик зат җитәкчесе тарафыннан расланган техник паспорты нигезендә аларга эшләнгән экспликация.

3. Арендага бирү өчен билгеләнгән җиһазларның юридик зат җитәкчесе тарафыннан расланган исемлеге (арендага бирелерлек җиһаз булган очракта).

4. Дәүләт мөлкәтенең билгеле бер вакыт чорына аренда (аренда түләве ставкалары) бәясе турында бәйсез бәя куючының отчеты.

5. Мөлкәтне арендага бирүнең максатка ярашлылыгын нигезләү.

6. Арендага бирү өчен тәкъдим ителә торган биналар һәм бүлмәләрнең электрон форматтагы фотосурәтләре.

**Автоном учреждениеләр өчен өстәмә:**

7. Автоном учреждение күзәтчелек советының мөлкәт белән эш итү буенча алыш-биреш ясау турындагы тәкъдимнәре.

**Казна учреждениеләре** (күчемле мөлкәтне арендага биргәндә) **һәм бюджет учреждениеләре өчен** (бюджет учреждениеләре тарафыннан «Коммерциячел булмаган оешмалар турында» федераль законның 9.2. статьясы 13 пунктында билгеләп куелган критерийларга туры килүче зур алыш-биреш, яки башкарылуында “Коммерциячел булмаган оешмалар турында» федераль законның 27 статьясында билгеләп куелган критерийларга туры килүче кызыксыну булган алыш-биреш башкарылганда) **өстәмә:**

8. Гамәлгә куючы ризалыгы.

**Балалар өчен социаль инфраструктура объекты булып торучы учреждениеләр өчен өстәмә:**

9. Аренда килешүе нәтиҗәләренең җитәкче кул куйган учреждениене гамәлгә куючы тарафыннан килештерелгән эксперт бәяләмәсе (мәгариф учреждениеләре һәм балалар медицина учреждениеләре өчен Мәгариф буенча федераль агентлыкның 24.03.2006 ел, № 16-55-88ин/02-12 хаты белән расланган форма буенча).

**Арендага мәдәни мирас объектларын биргән очракта өстәмә:**

10. Татарстан Республикасы милкендә булган мәдәни мирас объектыннан файдаланучыны сак йөкләмәсе күчермәсе. Ул:

федераль әһәмияттәге мәдәни мирас объектларына карата – Татарстан Республикасының мәдәни мирас объектларын (башкарма хакимиятнең массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә контрольлек һәм күзәтчелек итү буенча һәм мәдәни мирасны саклау буенча функцияләр башкаручы федераль орган белән килешү буенча) һәм төбәк әһәмиятендәге мәдәни мирас объектларын саклау өлкәсендә вәкаләтле башкарма хакимият органы тарафыннан;

җирле (муниципаль) әһәмияттәге мәдәни мирас объектларына карата – муниципаль районнарның яки шәһәр округларының башкарма органнары тарафыннан рәсмиләштерелгән.

**Дәүләт мөлкәтен сатулашу уздырмыйча гына арендага бирүне килештергәндә өстәмә:**

11. Күздә тотылган Арендаторның документлары:

**Юридик затлар өчен:**

устав яки нигезләмә күчермәсе;

җитәкче вазыйфасына билгеләп кую турындагы карар күчермәсе.

**Шәхси эшкуарлар өчен:**

дәүләт мөлкәтен арендага бирү турында гариза күчермәсе.

Документларның барлык күчермәләре бер экземплярда тапшырыла һәм юридик зат җитәкчесе тарафыннан раслана.

Гариза һәм аңа теркәлгән документларны гариза бирүче кәгазь форматта түбәндәге ысуллар белән тапшыра ала:

шәхсән үзе (ышанычнамә нигезендә гариза бирүче исеменнән эш итүче зат);

почта аша.

Техник мөмкинлекләр булган очракта мөрәҗәгать һәм аңа беркетелгән документлар электрон документлар рәвешендә Татарстан Республикасы бердәм ведомствоара электрон документ әйләнеше системасы аша бирелә ала. Документларны электрон документлар рәвешендә бирү өчен мәҗбүри шарт булып аларны электрон имза белән, 6 апрель 2011 ел, № 63-ФЗ Федераль закон һәм 27 июль 2010 ел, № 210-ФЗ Федераль законга туры китереп имзалау тора.»;

2.6 пунктта:

«Стандартка таләпләр эчтәлеге» графасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Ведомствоара мәгълүмати арадашлык кысаларында алыналар:

1. Юридик затларның бердәм дәүләт реестрыннан (алга таба – ЕГРЮЛ) гариза бирүче булган юридик зат турында өземтә, яки Федераль салым хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсеннән (алга таба – ТР буенча ТР ФСХИ) Юридик затларның бердәм дәүләт реестры язуы бите;

2. Арендага биреләсе күчемсез милек турында Бердәм дәүләт күчемсез милек реестрыннан өземтә (алга таба – ЕГРН) өземтә Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәтенең Татарстан Республикасындагы идарәсеннән (алга таба – ТР буенча Росреестр).

3. Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең мәдәни мирас объектларын саклау өлкәсендә вәкаләтле органыннан мөлкәтнең Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектына (тарихи һәм мәдәни ядкәрләр) кертелүе турында белешмә – Татарстан Республикасы Мәдәни мирас объектларын саклау комитетыннан (алга таба – ТР Комитеты).

4. Мәҗбүри медицина иминиятләштерүе өлкәсендә эшчәнлек алып баручы медицина оешмалары реестрыннан өземтә - Татарстан Республикасы Мәҗбүри медицина иминиятләштерүе территориаль фонды (алга таба – ТФОМС РТ)

Гариза бирүче әлеге пунктта күрсәтелгән белешмәләр булган документларны үзе тапшыра ала, шул исәптән, мөмкинлек булган очракта электрон формада да.

Гариза бирүченең өстә күрсәтелгән белешмәләр булган документларны тапшырмавы дәүләт хезмәтен күрсәтүдән баш тартуга сәбәп булып тормый.

Гариза бирүче тапшырырга хокуклы документларын алу һәм тапшыру тәртибе әлеге Регламентның 2.5 пунктында күрсәтелгән.

Гариза бирүчедән түбәндәгеләрне таләп итү тыела:

дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүче органнарында, башка дәүләт органнарында, җирле үзидарә органнарында яисә дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүдә катнашучы башка дәүләт органнары яки җирле үзидарә органнарының ведомствосында булган һәм башка оешмаларда булган документларны. Искәрмә булып №210-ФЗ Федераль законның 7 статьясындагы 6 өлешендә каралган документлар тора.

дәүләт хезмәте күрсәтү өчен зарури документларны кабул итүдән беренчел баш тартканда белешмәнең булмавы һәм (яки) дөрес булмавы күрсәтелмәгәндә. Түбәндәге очраклар искәрмә булып тора:

дәүләт хезмәте күрсәтү турында беренче тапкыр документлар тапшырганнан соң, дәүләт хезмәте күрсәтүгә кагылышлы норматив хокукый актларның таләпләре үзгәрү;

документлар кабул итүдән беренче тапкыр баш тартканнан соң, дәүләт хезмәте күрсәтү турында мөрәҗәгатьтә һәм дәүләт хезмәте күрсәтү өчен яисә дәүләт хезмәте күрсәткәндә зарури булган һәм алдан тапшырылган документлар комплектына кертелмәгән документларда хаталар булуы;

дәүләт хезмәте күрсәтү өчен яисә дәүләт хезмәте күрсәткәндә зарури булган документлар кабул итүдән беренче тапкыр баш тартканнан соң, документларның срогы чыгуы яки мәгълүматның үзгәрүе;

дәүләт хезмәте күрсәтүче органның вазыйфаи затының, дәүләт хезмәткәренең дәүләт хезмәте күрсәтү өчен яисә дәүләт хезмәте күрсәткәндә зарури булган документлар кабул итүдән беренче тапкыр баш тартканда хаталы яки хокукларга каршы гамәленең (гамәл кылмавының) документаль расланган факты (билгеләре) ачыклануы. Бу хакта гариза бирүчегә дәүләт хезмәте күрсәтүче орган җитәкчесе имзасы куелган хат аша белдерелә, кыенлык тудырылуы өчен гафу үтенелә.»;

3 бүлектә:

3.3.1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.3.1. Гариза бирүче әлеге Регламентның 2.5 пунктында күрсәтелгән документлар беркетелгән мөрәҗәгатен Министрлыкка тапшыра.

Техник мөмкинлекләр булган очракта мөрәҗәгать һәм аңа беркетелгән документлар «Интернет» мәгълүмати телекоммуникацияләр челтәрен кулланып, электрон документлар рәвешендә бирелә ала. Документларны электрон документлар рәвешендә бирү өчен мәҗбүри шарт булып аларны электрон имза белән, 6 апрель 2011 ел, № 63-ФЗ Федераль закон һәм Федерального закона от 27 июль 2010 ел, № 210-ФЗ Федераль законга туры китереп имзалау тора.»;

3.3.2 пунктның алтынчы абзацына түбәндәге сүзләрне өстәргә «, электрон формадагы мөрәҗәгатьнең һәм документларның ялларда (бәйрәм көнендә) керүе искәрмә булып тора»

3.4.1 пунктта:

икенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә::

«гариза бирүче булган юридик зат турында Юридик затларның бердәм дәүләт реестрыннан белешмә бирү турында, ТР буенча ФСХИдан;»;

дүртенче абзацта «ТР Мәдәният министрлыгы» сүзен «ТР Комитеты» сүзе белән алмаштырырга;

3.5.1 пунктның икенче абзацында слово «дүрт көнлек» сүзләрен «ике көнлек» сүзләре белән алмаштырырга;

3.5.2 пунктның икенче абзацында «тугыз көнлек» сүзләрен «дүрт көнлек» сүзләре белән алмаштырырга;

3.5.3 пунктның икенче абзацында «ике эш көне эчендә» сүзләрен «бер эш көне эчендә» сүзләре белән алмаштырырга;;

3.5.4 пунктның өченче абзацында «ике эш көне эчендә» сүзләрен «бер эш көне эчендә» сүзләре белән алмаштырырга;

3.5.5 пунктның бишенче абзацында «дүрт көнлек» сүзләрен «ике көнлек» сүзләре белән алмаштырырга;

3.5.8 пунктның икенче абзацында «эчендә» сүзенә «бер эш көне» сүзләрен өстәргә;

3.6.1 пунктның икенче абзацында «өч эш көне эчендә» сүзләрен «бер эш көне эчендә» сүзләре белән алмаштырырга;

5 бүлекне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

**«5. Министрлыкның, Министрлыкның вазыйфаи затының яисә дәүләт хезмәткәренең карарларына, кылган (кылмаган) гамәлләренә карата судка кадәр (судтан тыш) тәртиптә шикаять белдерү**

5.1. Гариза бирүчеләр дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы Министрлыкның, Министрлыкның вазыйфаи затының яисә дәүләт хезмәткәренең карарларына һәм кылган (кылмаган) гамәлләрен зарланып судка кадәр Министрлыкка шикаять бирергә хокуклы.

Дәүләт хезмәте күрсәтү буенча министрның карарына, кылган (кылмаган) гамәленә шикаять Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына бирелә

5.2. Гариза бирүче түбәндәге очракларда да шикаять белән мөрәҗәгать итә ала:

1) дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза бирүченең запросын теркәү срогы бозылганда;

2) дәүләт хезмәте күрсәтү срогы бозылганда;

3) гариза бирүчедән дәүләт хезмәте күрсәтү өчен Россия Федерациясенең норматив-хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив-хокукый актларында күздә тотылмаган документлар яки мәгълүмат, гамәлләр кылуны таләп иткәндә;

4) дәүләт хезмәте күрсәтү өчен гариза бирүчедән Россия Федерациясе норматив-хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив-хокукый актларында күздә тотылган документларны кабул итеп алудан баш тартканда;

5) дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тартканда, әгәр баш тартуга нигезләр федераль законнар һәм Россия Федерациясенең алар нигезендә кабул ителгән башка норматив-хокукый актлары, Татарстан Республикасы законнары һәм норматив-хокукый актлары нигезендә күздә тотылмаса;

6) дәүләт хезмәте күрсәтү өчен гариза бирүчедән Россия Федерациясенең норматив-хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив-хокукый актларында күздә тотылмаган түләү таләп иткәндә;

7) Министрлык, Министрлыкның вазыйфаи заты дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документлардагы ялгыш язуларны һәм хаталарны төзәтүдән баш тартканда яки мондый төзәтүләрнең билгеләнгән срогын бозганда;

8) дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе буенча документлар бирү срогын яки тәртибен бозганда;

9) дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатканда, әгәр андый туктату федераль законнар һәм Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актлары, Татарстан Республикасы законнары һәм башка норматив хокукый актлары белән каралмаган булса.

10) дәүләт хезмәте күрсәткәндә гариза бирүчедән дәүләт хезмәте күрсәтү өчен яисә дәүләт хезмәте күрсәткәндә зарури булган документлар кабул итүдән беренче тапкыр баш тартканда булмавы яки дөрес түгеллеге күрсәтелмәгән мәгълүматны яки документларны таләп итү. №210-ФЗ Федераль законның 1 статьясындагы 4 өлешендә каралган очраклар искәрмә булып тора.

5.3. Шикаять язмача кәгазьдә яисә электрон формада бирелә.

Шикаять почта аша, күпфункцияле үзәк аша, “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәреннән файдаланып, Министрлыкның рәсми сайты (http://mzio.tatarstan.ru), Татарстан Республикасының Дәүләти һәм муниципаль хезмәт күрсәтүләр порталы (http://uslugi.tatar.ru), Дәүләти һәм муниципаль хезмәт күрсәтүләрнең (функцияләрнең) бердәм порталы (http://www.gosuslugi.ru) аша җибәрелергә, шулай ук гариза бирүчене шәхсән кабул итү барышында кабул ителергә мөмкин.

5.4. Шикаять түбәндәге мәгълүматлардан торырга тиеш:

1) дәүләт хезмәте күрсәтүче органның атамасы, аның карарларына һәм кылган (кылмаган) гамәлләренә шикаять белдерелгән дәүләт хезмәте күрсәтүче вазыйфаи затының яки дәүләт хезмәткәренең исеме;

2) гариза бирүченең фамилиясе, исеме, әтисенең исеме (соңгысы - булганда), гариза бирүче физик затның яшәү урыны турында мәгълүматлар яисә гариза бирүче юридик затның урнашкан урыны турында мәгълүматлар, шулай ук элемтәгә керү өчен телефон номеры (номерлары), электрон почта адресы (адреслары) (булганда) һәм мөрәҗәгать итүчегә җавап җибәрелергә тиешле почта адресы;

3) дәүләт хезмәте күрсәтүче органның, аның дәүләт хезмәте күрсәтүче вазыйфаи затының яки дәүләт хезмәткәренең шикаять белдерелә торган карарлары һәм кылган (кылмаган) гамәлләре турында белешмә;

4) гариза бирүченең дәүләт хезмәте күрсәтүче органның, аның вазыйфаи затының яки дәүләт хезмәткәренең карары һәм кылган (кылмаган) гамәлләре белән килешмәвенә дәлилләре.

5.5. Шикаятькә анда күрсәтелгән шартларны раслый торган документлар теркәлә ала. Бу очракта теркәлгән документлар исемлеге китерелә.

5.6. Шикаятьне карап тикшерү вакыты – аны регистрацияләгәннән соң 15 көн. Министрлыкның гариза бирүчедән документларын кабул итеп алудан баш тартуга яки ялгыш язуларны һәм хаталарны төзәтүдән баш тартуга яки мондый төзәтүләрнең билгеләнгән срогын бозуга карата шикаять белдерелгән очракта - аны теркәгән көннән алып биш эш көне эчендә

5.7. Шикаятьне карап тикшерү нәтиҗәләре буенча түбәндәге карарларның берсе кабул ителә:

1) шикаятьне канәгатьләндерә, шул исәптән кабул ителгән карарны юкка чыгару рәвешендә, дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документларда җибәрелгән ялгыш язуларны һәм хаталарны төзәтү, Россия Федерациясенең норматив-хокукый актлары, Татарстан Республикасының норматив-хокукый актлары нигезендә түләтү күздә тотылмаган акчаларны гариза бирүчегә кире кайтарып бирү рәвешендә;

2) шикаятьне канәгатьләндерүдән баш тартыла.

5.8. Әлеге Регламентның 5.7 пунктында күрсәтелгән карар кабул ителгәннән соң килүче көннән дә соңга калмыйча, гариза бирүчегә язмача һәм, гариза бирүченең теләгенә карап, электрон рәвештә, шикаятьне карап тикшерү нәтиҗәләре турында нигезле җавап җибәрелә.

5.9. Шикаять канәгатьләндерелә дип танылган очракта, гариза бирүчегә Регламентның 5.8 пунктында күрсәтелгән җавапта дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә ачыкланган тәртип бозуларны бетерү максатында Министрлык кылган гамәлләр турында мәгълүмат бирелә, тудырылган уңайсызлыклар өчен гафу үтенелә, гариза бирүче дәүләт хезмәте алу өчен кылырга тиешле гамәлләр турында мәгълүмат китерелә.

5.10. Шикаять канәгатьләндерелми дип танылган очракта, гариза бирүчегә Регламентның 5.8 пунктында күрсәтелгән җавапта кабул ителгән карарның сәбәпләре ачыклана, кабул ителгән карарга шикаять белдерү тәртибе турында мәгълүмат бирелә.

5.11. Шикаятьне карау барышында яки аның нәтиҗәләре буенча, административ хокук бозу билгеләре яки җинаять ачыкланса, шикаятьләрне карау вәкаләтләре бирелгән вазыйфаи зат булган материалларны тиз арада прокуратура органнарына юллый.»;

Татарстан Татарстан Республикасы милкендә булган мөлкәтне арендага бирүне килештерү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына 3 нче кушымтада «ТР Мәдәният министрлыгы» сүзен «ТР Комитеты» сүзе белән алмаштырырга.